ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
НУРЛАТСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
29.06.2021

КАРАР
№ 614

2021 елның II яртыеллыгына Нурлат муниципаль районының халыкка һәм башка кулланучыларга күрсәтелә торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында

«Коммуналь комплекс оешмалары тарифларын җайга салу нигезләре турында» 2004 елның 30 декабрендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Коммуналь комплекс оешмалары эшчәнлеге өлкәсендә тарифлар, өстәмәләр һәм чик индекслар бәяләрен билгеләү һәм җайга салу нигезләре турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2008 елның 14 июлендәге 520 номерлы карары һәм «Коммуналь хезмәт күрсәтүләр өчен гражданнарның түләү күләмен үзгәртүнең иң чик индексларын формалаштыру нигезләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 28 августындагы 708 номерлы карары нигезендә, Нурлат муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Расларга һәм 2021 елның 1 июленнән гамәлгә кертергә:

- социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча һәм күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре өчен түләү күләме (1 нче кушымта);

- ИК, ТМШ идарәсендә булган торак урыннар милекчеләре өчен капиталь ремонт өчен түләү күләме (2 нче кушымта);

- Нурлат шәһәре буенча муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннар яллаучыларга торак урын яллаган өчен түләү күләме (3 нче кушымта);

2. Нурлат муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 30 июнендәге 23 номерлы «Нурлат муниципаль районының халыкка һәм башка кулланучыларга 2020 елның II яртыеллыгында тапшырыла торган торак-коммуналь хезмәтләргә тарифларны раслау турында» карарын үз көчен югалткан дип танырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында, шул исәптән Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче

Р.Р. Хәмзин

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 29.06.2021 ел, №. 614 карарына 1 нче кушымта

Социаль наем шартнамәләре һәм муниципаль торак фондының торак урыннарына наем шартнамәләре буенча һәм күпфатирлы торак йорт белән идарә итү ысулын сайлау турында карар кабул итмәгән торак урыннар милекчеләре өчен торак хезмәтләре тарифлары

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Коммуналь түләүләр буенча Бердәм исәп-хисап үзәге хезмәтләре белән торак фонды белән идарә итү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 2,97 |
| Коммуналь түләүләр буенча Бердәм исәп-хисап үзәге хезмәтләреннән башка торак фонды белән идарә итү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 3,02 |
| Йорт яны территориясен җыештыру һәм чистарту | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 3,06 |
| Торак фондын агымдагы ремонтлау һәм йорт яны территориясен төзекләндерү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 3,03 |
| Йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә һәм исәпкә алуның гомумйорт приборлары белән санитар-техник җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 1,39 |
| шул исәптән исәпкә алуның гомумйорт приборларына хезмәт күрсәтү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 0,14 |
| Йорт эчендәге сууткәргеч-канализация челтәрләренә һәм исәпкә алуның гомумйорт приборларыннан башка санитар-техник җиһазларга техник хезмәт күрсәтү һәм ремонт | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 1,25 |
| Үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләренә җылылык энергиясен исәпкә алуның гомумйорт узелы белән техник хезмәт күрсәтү һәм ремонтлау | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 1,46 |
| шул исәптән җылылык энергиясен исәпкә алу гомумйорт узелына хезмәт күрсәтү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 0,53 |
| Җылылык энергиясен исәпкә алуның гомумйорт узелыннан башка, үзәк җылытуның йорт эчендәге челтәрләрен ремонтлау һәм төзекләндерү | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 0,93 |
| Газ белән тәэмин итүнең йорт | Торак урынның гомуми мәйданы | 0,60 |

| | | |
|---|---|---|
| эчендәге челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | кв.м. айлык түләү | |
| Йорт эчендәге электр челтәрләрен ремонтлау һәм карап тоту | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 0,95 |

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 29.06.2021 ел, № 614 карарына 2 нче кушымта

УК, ТМШ идарәсендә булган торак урыннар милекчеләре өчен капиталь ремонтка тариф

| Хезмәтнең исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак бинага капиталь ремонт | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 6,38 |

Нурлат муниципаль районы Нурлат шәһәре Башкарма комитетының 29.06.2021 ел, № 614 карарына 3 нче кушымта

Муниципаль торак фондының торак урыннарына социаль наем шартнамәләре буенча торак урыннарны наемга алучылар өчен тариф

| Хезмәтнең исеме | Түләү алына торган үлчәү берәмлеге | Хезмәт берәмлеге өчен тариф (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 |
| Торак урын алу | Торак урынның гомуми мәйданы кв.м. айлык түләү | 7,94 |